КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 15 июнь г.Казань № 460

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары һөнәр белеме бирүче «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» федераль дәүләт бюджет белем учреждениесе фәнни-белем бирү кластерын оештыру турында» 2011 ел, 12 апрель, 288 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары һөнәр белеме бирүче «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» федераль дәүләт бюджет белем учреждениесе фәнни-белем бирү кластерын оештыру турында» 2011 ел, 12 апрель, 288 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 15 июнь, 516 нчы; 2014 ел, 18 октябрь, 770 нче; 2015 ел, 25 декабрь, 983 нче, 2016 ел, 27 длекабрь, 1002 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» сүзләрен «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университеты» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең фәнни-белем бирү кластерын төзү турында (алга таба - фәнни-мәгариф кластеры) тәкъдимнәрен кабул итәргә.»;

2 пунктның икенче һәм өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университеты» федераль дәүләт югары белем бирү мәгариф учреждениесенең фәнни-мәгариф кластеры составы«;

«Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университеты» федераль дәүләт югары белем бирү мәгариф учреждениесенең фәнни-мәгариф кластерының Координация советы турында нигезләмә.»;

3 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының фәнни-белем бирү кластеры составына керүче Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларын гамәлгә куючыларның вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы тәкъдимнәрен төзелгән килешүләр нигезендә «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе белән фәнни-мәгариф кластеры составына керүче Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларының үзара хезмәттәшлеген оештыру турында.»;

3 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы яки гамәлгә куючы вәкаләтләре нигезендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, фәнни-мәгариф кластеры составына керүче Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары һәм «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе арасында төзелә торган килешү формасын эшләргә һәм расларга.»;

3 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе белән берлектә фәнни-мәгариф кластеры составына керүче һөнәри белем бирү оешмалары гамәлгә ашыра торган белгечлекләр буенча белем бирү эшчәнлегенә лицензияләр алу эшен тәэмин итәргә.»;

6 пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Сспорт министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга

әлеге карар белән расланган «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең фәнни-мәгариф кластеры составында:

исемендә «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» сүзләрен «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университеты» сүзләренә алмаштырырга;

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университеты» федераль дәүләт югары белем бирү мәгариф учреждениесе»;»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Түбән Кама педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе;

«Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе;

«Муса Җәлил исемендәге Минзәлә педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе;

«Казан медицина көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе;

«Казан педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе».»;

әлеге карар белән расланган «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең фәнни-мәгариф кластерының координация советы турында нигезләмәдә:

исемендә һәм 1.2 пунктында «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» сүзләрен «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университеты» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин